КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 4 март г.Казань № 164

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы үсеше өчен аеруча перспективалы һәм әһәмиятле өлкәләрдә Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2024 ел, 26 октябрь, 926 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 28 октябрь, 874 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында яшь галимнәргә ярдәм итү өчен республика фәнни премияләрен бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның алтынчы абзацына «, конкурс үткәрелгәннән алдагы елдан соң кимендә биш елдан соң башкару һәм (яисә) бастырып чыгару» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта:

«е» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«ж» пунктчасында «республика» сүзен «Татарстан Республикасында яшь галимнәр һәм яшьләр фәнни коллективлары уздыра торган фәнни тикшеренүләргә

ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы грантлары һәм республика грантлары» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «тегелгән һәм битләре буенча номерланган» сүзләрен «тегелгән, битләре буенча номерланган һәм конкурста катнашучы имзасы белән беркетелгән» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктка «20 һәм аннан күбрәк балл» сүзләреннән соң «, яисә 20 яки аннан күбрәк баллны конкурска гаризаларның берсе генә җыйды» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин